**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об установлении ограничительных мероприятий (карантина) на отдельной территории Лаишевского района Республики Татарстан в связи с ее неблагополучием по заболеванию высокопатогенным гриппом птиц и угрозой его распространения

В связи с выявлением заболевания высокопатогенным гриппом птиц на территории птицеводческого предприятия, принадлежащего обществу с ограниченной ответственностью «Птицекомплекс Лаишевский» (далее – ООО «Птицекомплекс Лаишевский»), расположенного в Лаишевском районе Республики Татарстан, и угрозой его распространения, в соответствии со статьей $3^1$, 17 Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии», приказом Министерства сельского хозяйства Российской Федерации от 27 марта 2006 года № 90 **постановляю:**

1. Установить ограничительные мероприятия (карантин) по высокопатогенному гриппу птиц на территории птицеводческого предприятия, принадлежащего ООО «Птицекомплекс Лаишевский», расположенного по адресу: Республика Татарстан, Лаишевский район, поселок совхоза им. 25 Октября, улица Почтовая, д. 19, на период до их отмены.

2. Утвердить прилагаемый Перечень ограничений на оборот птицы, продуктов птицеводства, кормов и кормовых добавок на территории птицеводческого предприятия, принадлежащего ООО «Птицекомплекс Лаишевский», расположенного по адресу: Республика Татарстан, Лаишевский район, поселок совхоза им. 25 Октября, улица Почтовая, д. 19, на период до их отмены.

3. Определить:

эпизоотический очаг в пределах территории птицеводческого предприятия, принадлежащего ООО «Птицекомплекс Лаишевский», расположенного по адресу: Республика Татарстан, Лаишевский район, поселок совхоза им. 25 Октября, улица Почтовая, д.19 (далее – неблагополучный пункт);

угрожаемую зону в пределах территории радиусом 5 км от границ неблагополучного пункта, включая поселок совхоза им. 25 Октября, поселок

Александровский, село Среднее Девятово, деревню Смолдеярово Лаишевского района Республики Татарстан;

зону наблюдения в пределах территории радиусом 10 км от границ неблагополучного пункта, включая город Лаишево, село Именьково, село Чирпы, село Емельяново, деревню Маматово, село Пелево, село Державино, село Бутыри, деревню Верхние Кармачи, поселок Нижние Кармачи Лаишевского района Республики Татарстан.

4. Главному управлению ветеринарии Кабинета Министров Республики Татарстан разработать и утвердить план мероприятий по ликвидации очага высокопатогенного вируса гриппа птиц и предотвращению распространения возбудителя болезни на территории Республики Татарстан.

5. Контроль за исполнением настоящего Указа возложить на Кабинет Министров Республики Татарстан.

6. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ *
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань,Кремль
10 мая 2017 года
№ УП-372

Приложение
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «10» мая 2017 года

№ УП - 372

# ПЕРЕЧЕНЬ

## ограничений на оборот птицы, продуктов птицеводства, кормов и кормовых добавок на территории птицеводческого предприятия, принадлежащего ООО «Птицекомплекс Лаишевский», расположенного по адресу: Республика Татарстан, Лаишевский район, поселок совхоза им. 25 Октября, улица Почтовая, д.19, на период до их отмены

На период действия ограничительных мероприятий (карантина) на территории неблагополучного пункта:

- закрыть доступ на объект посторонним лицам и транспорту на объектах;
- не допускать посещение работниками неблагополучных птичников, кроме персонала, непосредственно их обслуживающего, и дополнительно закрепленных на период проведения мероприятий работников и специалистов в области ветеринарии;
- ограничить передвижение персонала, обслуживающего неблагополучную группу птиц, по территории организации, исключение его контакта с другими птицами и ухаживающими за ними лицами;
- организовать бескровный убой больной птицы, сбор павшей и убитой птицы в герметичную тару;
- отвести в пределах территории организации участок для сжигания трупов птиц;
- провести при массовом бескровном убое больной птицы ее захоронение в установленном порядке в условиях, исключающих рассеивание предполагаемого возбудителя болезни во внешней среде;
- прекратить перемещение птицы внутри организации и вывоз из нее птицы, яиц и других продуктов птицеводства, а также вывоз кормов, инвентаря, оборудования, помета;
- организовать проведение дезинфекции птичников, включая при необходимости дезинфекцию в присутствии птицы, прилегающей территории и дорог внутрихозяйственного назначения;
- изолировать больную птицу и не допустить посещения инфицированных птичников и выгулов людьми, кроме персонала, непосредственно обслуживающего данный объект, и дополнительно

закрепленных на период проведения мероприятий работников и специалистов в области ветеринарии;

- прекратить выгул или иное использование птицы за границами объекта;

- приостановить торговлю птицей;

- приостановить отгрузку продукции убоя;

- складировать продукцию убоя, полученного от подозреваемой в инфицировании птицы, в отдельных складских и холодильных помещениях;

- не допускать к работе, предполагающей непосредственный контакт с подозреваемой в заражении птицей, граждан в возрасте свыше 65 и моложе 18 лет, лиц, имеющих хронические болезни органов дыхания и иммунной системы, лиц с признаками любых болезней и недомоганий;

- закрыть все дороги (тропы), ведущие из неблагополучного пункта, выставить необходимое количество круглосуточных контрольно-пропускных постов, оборудованных дезбарьерами, пароформалиновыми камерами для обработки одежды и дезинфекционными установками, с круглосуточным дежурством, с привлечением ветеринарных инспекторов и сотрудников правоохранительных органов;

- ограничить передвижение транспорта в зоне карантина, при этом допущенный транспорт подлежит обязательной дезинфекции на въезде и выезде из карантинной зоны;

- закрепить в неблагополучном пункте постоянный транспорт без права выезда за пределы карантинной зоны, а на контрольно-пропускном пункте оборудовать площадки для перевалки доставляемых грузов;

- оборудовать вход в птицеводческие помещения, расположенные на территории эпизоотического очага, дезбарьерами и дезковриками для обработки обуви и транспорта, заправленными раствором эффективного при гриппе птиц дезинфицирующего средства;

- провести мероприятия по убою и уничтожению восприимчивого поголовья.

---

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Лаеш районының аерым территориясендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аның иминлексезлеге сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында**

Татарстан Республикасының Лаеш районында урнашкан «Лаеш кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте карамагындагы кошчылык предприятиесе территориясендә кошларның йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү очрагы ачыклану һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2006 елның 27 мартындагы 90 номерлы карары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы, Лаеш районы, 25 Октябрь исемендәге совхоз поселогы, Почта урамы, 19 йорт адресы буенча урнашкан «Лаеш кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте карамагындагы кошчылык предприятиесе территориясендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы вирусы барлыкка килүгә бәйле рәвештә, аларны бетерү турында карар кабул ителгәнгә кадәр, чикләү чараларын (карантин) кертергә.

2. Татарстан Республикасы, Лаеш районы, 25 Октябрь исемендәге совхоз поселогы, Почта урамы, 19 йорт адресы буенча урнашкан «Лаеш кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте карамагындагы кошчылык предприятиесе территориясендә кош, кошчылык продуктларын, азык һәм азыкка өстәмәләрнең әйләнешенә чикләүләр исемлеген, аларны бетерү турында карар кабул ителгәнгә кадәр, расларга.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы, Лаеш районы, 25 Октябрь исемендәге совхоз поселогы, Почта урамы, 19 йорт адресы буенча урнашкан «Лаеш кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – имин булмаган пункт) карамагындагы кошчылык предприятиесе территориясе чикләрендә эпизоотия чыганагын;

имин булмаган пункт чикләреннән 5 км радиустагы территория чикләрендә, Татарстан Республикасы Лаеш районының 25 Октябрь

исемендәге совхоз поселогын, Александровка поселогын, Урта Девятово авылын, Смолдеярово авылын кертеп, куркыныч янау зонасын;

имин булмаган пункт чикләреннән 10 км радиустагы территория чикләрендә, Татарстан Республикасы Лаеш районының Лаеш шәһәрен, Имән Кискә авылын, Чырпы авылын, Емельяново авылын, Мәмәт авылын, Пәрәү авылын, Державино авылын, Бутыри авылын, Югары Кармачы авылын, Түбән Кармачы поселогын кертеп, күзәтү зонасын.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йогышлылыгы югары булган кош гриппы вирусы чыганагын бетерү һәм авыру чыганагының Татарстан Республикасы территориясендә таралуын булдырмау буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2017 ел, 10 май
№ ПУ-372

Татарстан Республикасы
Президентының
2017 елның «_10_» _маендагы_
ПУ-_372_ номерлы Указына
кушымта

«Лаеш кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Татарстан Республикасы, Лаеш районы, 25 Октябрь исемендәге совхоз поселогы, Почта урамы, 19 нчы йорт адресы буенча урнашкан кошчылык предприятиесе территориясендә, аларны бетерү турында карар кабул ителгәнче, кош, кошчылык продуктлары, азык һәм азыкка өстәмәләр әйләнешенә чикләүләр

# ИСЕМЛЕГЕ

Чикләү чаралары (карантин) гамәле вакытында имин булмаган пункт территориясендә:

- объектка чит кешеләр керүне һәм транспорт керүне туктатырга;
- имин булмаган кош абзарларына турыдан-туры хезмәт күрсәтүче персоналдан һәм чаралар уздырыла торган вакытка өстәмә рәвештә объектка беркетелгән ветеринария өлкәсендәге хезмәткәрләр һәм белгечләрдән тыш, бу кош абзарларына хезмәткәрләргә керүне тыярга;
- кошларның иминлексез төркеменә хезмәт күрсәтүче персоналның оешма территориясе буйлап йөрүен чикләргә, аларның башка кошлар һәм аларга хезмәт күрсәтүче затлар белән аралашуын булдырмаска;
- чир йоктырган кошларны кан чыгармыйча юк итүне, үлгән һәм юк ителгән кошларны герметик тарага җыюны оештырырга;
- оешма территориясе чикләрендә кош үләксәләрен ягу өчен урын әзерләргә;
- кан чыгармыйча массачыл төстә кошларны юк итү вакытында, авыру тудыручы дип күздә тотылган чыганакның әйләнә-тирә мохиттә таралуын булдырмау шартларында, үләксәләрне күмүне билгеләнгән тәртиптә уздырырга;
- оешма эчендә кошларны күчерүне һәм аннан кошларны, йомыркаларны һәм башка кошчылык продуктларын, шулай ук кош азыгы, эш коралларын, җиһазларны, кош тизәген чыгаруны туктатырга;
- кош абзарларын, кирәк булганда, кошлар барында да дезинфекцияләүне кертеп, янәшәдәге территорияләрне һәм хуҗалык кулланышындагы юлларны дезинфекцияләүне оештырырга;
- авыру кошларны изоляцияләргә һәм авыру йоккан кош абзарларына, әлеге объектка турыдан-туры хезмәт күрсәтүче персоналдан һәм әлеге чаралар уздыра торган вакытка өстәмә рәвештә объектка беркетелгән ветеринария өлкәсендәге хезмәткәрләр һәм белгечләрдән кала, кешеләр кертмәскә;

- объект чикләреннән кошларны чыгаруны һәм аларны башкача файдалануны туктатырга;

- кошлар сатуны вакытлыча туктатырга;

- суелган кош итен чыгаруны вакытлыча туктатырга;

- авыру йоккан дип шикләнелгән кошларны складларга, аерым склад һәм суыткыч бүлмәләргә урнаштырырга;

- сулыш органнары һәм иммун системасының хроник авырулары булган 62 яшьтән узган һәм 18 яше тулмаган гражданнарны, төрле авыру билгеләре белән һәм үз-үзен начар хис итүче затларны авыру йоккан булырга мөмкин дип шикләнгән кошлар белән турыдан-туры элемтәгә керүне күздә тоткан эшкә кушмаска;

- имин булмаган пунктка илтүче барлык юлларны (сукмакларны) ябарга, кирәкле санда дезинфекцияләү киртәләре, кием-салымны эшкәртү өчен пароформалин камералары һәм дезинфекцияләү җайланмалары белән җиһазландырылган тәүлек әйләнәсе кизү торачак контроль-үткәрү постлары куярга, аларда эшләргә ветеринария инспекторларын һәм хокук саклау органнары хезмәткәрләрен җәлеп итәргә;

- карантин зонасында транспорт хәрәкәтен чикләргә, шул исәптән керү рөхсәт ителгән транспорт карантин зонасына кергәндә һәм аннан чыкканда мәҗбүри дезинфекцияләнергә тиеш;

- имин булмаган пунктта карантин зонасы чикләреннән чыгарга хокукы булмаган даими транспорт билгеләргә, ә контроль-үткәрү пунктында китерелгән йөкләрне бушату өчен мәйданчыклар җиһазландырырга;

- эпизоотия чыганагы территориясендәге кошчылык бүлмәләренә керү урыннарын аяк киемнәрен һәм транспортны эшкәртү өчен кош гриппын бетерүдә нәтиҗәле дезинфекцияләү чарасы салынган дезинфекцияләү киртәләре һәм дезинфекцияләү келәмнәре белән җиһазландырырга;

- авыруларга аеруча бирешүчән баш санын сую һәм юкка чыгару буенча чаралар уздырырга.